**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

« 23» 04 2020 ел          Яр Чаллы          № 1459

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетында хезмәтне саклау идарә системасы турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 19 августындагы «Хезмәтне саклау идарә системасы турында типлаштырылган нигезләмәне раслау турында» 438н номерлы боерыгы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1 Тукай муниципаль районы Башкарма комитетында хезмәтне саклау идарә системасы турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе          Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 23 04 1459 номерлы карарына кушымта

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында хезмәтне саклау идарә системасы турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетында хезмәтне саклау идарә системасы турында әлеге нигезләмә (алга таба – нигезләмә) хезмәтне саклау идарә системасының төп принципларын һәм структурасын, аның функцияләрен билгели һәм Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына нигезләнә.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетында хезмәтне саклау идарә системасы (алга таба – система) хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итүгә, хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән хезмәтне саклау мәсьәләләр буенча уртак гамәлләрнең оештыру формалары һәм ысуллары җыелмасыннан һәм аларның структур бүлекчәләреннән (юридик зат төземичә) (алга таба – структур бүлекчәләр) гыйбарәт.

3. Система кысаларында хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча идарә итү һәм җайга салу дәрәҗәләре булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Башкарма комитет Җитәкчесе тора.

II. Хезмәтне саклау өлкәсендә сәясәт

4. Хезмәтне саклау өлкәсендә сәясәт (алга таба – хезмәтне саклау сәясәте) хезмәтне саклауның дәүләт норматив таләпләрен үтәү һәм үз өстенә ирекле кабул ителгән йөкләмәләрне үтәүне гарантияли.

5. Хезмәтне саклау сәясәте түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) хезмәт эшчәнлеге процессында хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген саклау өстенлеге;

б) эш урыннарында хезмәт шартларының хезмәтне саклау таләпләренә туры килүе;

в) һәлакәтләрне һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлеге начараю очракларын, һөнәри авыруларны, шул исәптән һөнәри куркынычлар белән идарә итү юлы белән дә, кисәтү буенча эзлекле һәм өзлексез чараларны үтәү;

г) хезмәткәрләрнең шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алу, шул исәптән эш урыннарын проектлау, җиһазларны, шәхси һәм күмәк саклану чараларын сайлап алу юлы белән;

д) системаны өзлексез камилләштерү һәм нәтиҗәлелеген арттыру;

е) хезмәткәрләрне, алар вәкаләт биргән вәкиллекле органнарны тиешле ресурс белән тәэмин итү һәм мондый катнашуны бүләкләү юлы белән хезмәтне саклау белән идарә итүгә һәм хезмәтне саклау таләпләренә туры килгән хезмәт шартларын тәэмин итүгә мәҗбүри җәлеп итү;

ж) мөмкин кадәр имин хезмәт шартлары тәэмин итүдә шәхси кызыксыну;

з) үз эшчәнлеге үзенчәлегеннән чыгып, хезмәтне саклау өлкәсендә башка бурычларны үтәү.

## III. Хезмәтне саклау өлкәсендә максатлар

6. Хезмәтне саклау сәясәте хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүченең төп максатларын (алга таба – максатлар) үз эченә ала һәм аларга әлеге нигезләмәнең V бүлегендә каралган процедураларны эш бирүче тормышка ашыру юлы белән ирешелә.

7. Системаның төп максатлары:

а) хезмәтне саклау өлкәсендә оешма сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыру һәм аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

б) хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программасын эшләү һәм тормышка ашыру;

в) хезмәтне саклау буенча законнарны үтәүне тәэмин итә торган шартлар тудыру, шул исәптән хезмәт процессында кулланыла торган биналарны һәм корылмаларны, җайланмаларны, приборларны һәм хезмәт процессының техник чараларын эксплуатацияләүнең иминлеген тәэмин итү;

г) куркынычсыз хезмәт шартларын формалаштыру;

д) хезмәтне саклау таләпләрен үтәүне контрольдә тоту;

е) хезмәтне саклау буенча укыту һәм белемнәрне тикшерү, шул исәптән хезмәтне саклауны тәэмин итү өлкәсендә өзлексез белем бирү системасын булдыру һәм камилләштерү;

ж) хезмәт эшчәнлеген башкаручы затлар белән бәхетсезлек очракларын булдырмау;

з) персоналның, хезмәт эшчәнлеген башкаручы затларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларга дәвалау-профилактикалау хезмәте күрсәтүне оештыру, хезмәт режимнарының оптималь ярашуын булдыру, ялны оештыру.

## IV. Хезмәтне саклау өлкәсендә вазыйфаларны вазыйфаи затлар арасында бүлү

8. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты:

а) хезмәткәрләрнең, хезмәтне саклау таләпләренә туры килә торган хезмәт шартларын тәэмин итүне дә кертеп, хезмәтне саклауга хокукларын гарантияли;

б) хезмәткәрләрнең хезмәт һәм ял режимын үтәүне тәэмин итә;

в) хезмәткәрләрне бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан, һөнәри хәвеф-хәтәрләрдән вакытында иминләштерүне тәэмин итә;

г) хезмәтне саклау чараларын ресурслар белән тәэмин итүне оештыра;

д) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә үз акчалары хисабына мәҗбүри башлангыч (эшкә кергәндә) һәм вакытлы (хезмәт эшчәнлеге дәвамында) медицина тикшерүләре үткәрүне оештыра;

е) хезмәтне саклауны тәэмин итүгә караган хезмәт бурычларын үтәү өчен, компетентлыкның кирәкле дәрәҗәсен саклап калу зарурлыгын исәпкә алып, хезмәткәрләрне укытуның һәм һөнәри әзерләүнең, хезмәтне саклау буенча әзерлекне дә кертеп, билгеләнгән тәртибе үтәлешен тәэмин итә;

ж) тиешле квалификация таләпләрен канәгатьләндерүче һәм күрсәтелгән эшкә карата медицина ягыннан каршылыклары булмаган затларны мөстәкыйль эшкә кертә;

з) күмәк саклау чараларын сатып алуны һәм аларның эшләвен тәэмин итә;

и) хезмәт шартларын махсус бәяләүне оештыра;

к) хезмәткәрләргә эш урыннарында хезмәт шартлары, һөнәри куркыныч дәрәҗәләре, шулай ук аларга бирелә торган гарантияләр, тиешле компенсацияләр турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра;

л) хезмәтне саклау таләпләре нигезендә хезмәткәрләргә санитар-көнкүреш һәм медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итә;

м) һөнәри авыру сәбәпләрен тикшерүдә катнаша;

н) контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмәләренең үтәлешен оештыра.

9. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренең бурычлары:

а) хезмәтне саклау буенча инструкция таләпләрен, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәүне дә кертеп, хезмәт функцияләрен үтәү кысаларында хезмәтне саклау таләпләрен үтәү;

б) медицина тикшерүләрен узу;

в) хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын тикшерүдә катнашу;

г) үз эш урынын чисталыкта тоту;

д) структур бүлекчә җитәкчесенә үз эш урынын караганда ачыкланган җитешсезлекләр турында хәбәр итү;

е) шәхси һәм күмәк саклау чараларын һәм хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итүче җайланмаларны дөрес куллану;

ж) үзенең турыдан-туры җитәкчесенә яки югарыдагы җитәкчегә кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаган теләсә нинди хәл турында, һәр бәхетсезлек очрагы турында яки үз сәламәтлегенең торышы начарлану турында, шул исәптән кискен һөнәри авыру билгеләре турында хәбәр итү.

10. Хезмәтне саклау өчен җаваплы белгеч:

а) системаның эшләвен тәэмин итә;

б) эш бирүчедә хезмәтне саклау буенча оештыру эшенә җитәкчелек итә, эш бирүченең структур бүлекчәләре эшен координацияли;

в) һәркем файдалана алырлык урыннарда хезмәтне саклау буенча әзерлек үткәрү өчен күрсәтмә әсбаплар һәм заманча техник чаралар урнаштыруны оештыра;

г) Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәткәрләрне норматив хокукый һәм методик документлар белән тәэмин итүне контрольдә тота;

д) эш бирүчедә хезмәтне саклау таләпләрен, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәт законнарын, хезмәткәрләрнең хезмәт һәм ял режимнарын, контроль-күзәтчелек чаралары нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимияте органнарының күрсәтмәләрен үтәүне контрольдә тота;

е) хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын контрольдә тота;

ж) эш бирүченең структур бүлекчәләре тарафыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча чаралар эшләүне оештыра, аларның үтәлешен контрольдә тота;

з) хезмәтне саклау буенча локаль актларны эшләүдә һәм яңадан карауда катнаша;

и) хезмәтне саклау буенча әзерлек оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;

к) шәхси һәм күмәк саклану чараларын тәэмин итүне, бирүне, саклауны һәм аларның төзеклеген һәм дөрес кулланылышын контрольдә тота;

л) махсус кием һәм башка шәхси саклану чараларын, юдыручы һәм зарарсызландыручы матдәләр, сөт, дәвалау-профилактика азыклары бирү нормалары, шулай ук хезмәт өчен түләү күләмен һәм хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләре буенча өстәмә ялның дәвамлылыгын арттыру турында тәкъдимнәрне карый һәм яңадан карау буенча тәкъдимнәр кертә;

м) хезмәт шартларын махсус бәяләүне оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;

н) һөнәри куркынычлар белән идарә итүдә катнаша;

о) эш бирүченең структур бүлекчәләрендә хезмәтне саклау торышын тикшерә һәм үткәрә;

п) медицина тикшерүләрен үткәрүне оештыра;

р) булган җитешсезлекләрне һәм хезмәтне саклау таләпләрен бозу очракларын бетерү турында күрсәтмәләр бирә, аларның үтәлешен контрольдә тота.

11. Структур бүлекчә җитәкчесе:

а) эш бирүченең структур бүлекчәсендә хезмәтне саклау таләпләренә туры килгән хезмәт шартларын тәэмин итә;

б) системаның эшләвен тәэмин итә;

в) хезмәтне саклау өлкәсендә үзенә йөкләнгән бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыкка ия;

г) хезмәтне саклау өлкәсендәге вазыйфаларны үз кул астындагылар арасында бүлә, шул исәптән үз вәкаләтләренең бер өлешен тапшыра, аларның җаваплылык дәрәҗәсен билгели;

д) хезмәтне саклау буенча комитет (комиссия), хезмәткәрләре тарафыннан вәкаләт бирелгән органнар эшендә ярдәм итә;

е) эш бирүче акчалары хисабына мәҗбүри башлангыч (эшкә кергәндә) һәм вакытлы (хезмәт эшчәнлеге дәвамында) медицина тикшерүләрен вакытында үткәрүне тәэмин итә;

ж) тиешле квалификация таләпләрен канәгатьләндерүче һәм күрсәтелгән эшкә карата медицина ягыннан каршылыклары булмаган затларны мөстәкыйль эшкә кертә;

з) хезмәтне саклау буенча әзерлек үткәрүне оештыра;

и) хезмәт шартларын махсус бәяләүне оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;

к) структур бүлекчәдә хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышын контрольдә тотуны оештыруда һәм үткәрүдә катнаша;

л) контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмәләренең, хезмәтне саклау хезмәте (белгеч) күрсәтмәләренең үтәлешен тәэмин итә;

м) структур бүлекчәнең һәркем керә ала торган урыннарында, структур бүлекчә хезмәткәрләрен һәм башка затларны алар белән таныштыру өчен, хезмәтне саклау таләпләрен үз эченә алган документларның һәм мәгълүматның булуын тәэмин итә;

н) структур бүлекчәдә килеп чыккан килгән аварияләрдә һәм бәхетсезлек очракларында ашыгыч медицина ярдәмен чакыру һәм зыян күрүчеләрне медицина оешмасына алып баруны оештыру буенча чаралар күрә.

## V. Хезмәтне саклау өлкәсендә максатларга ирешүгә юнәлдерелгән процедуралар

12. Хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү процедурасын оештыру максатыннан эш бирүче түбәндәгеләрне билгели:

а) хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау, аны тикшерү, яклау һәм үстерү буенча кирәкле һөнәри компетентлыгына таләпләр;

б) хезмәтне саклау буенча стажировка үтүче хезмәткәрләрнең, һәр һөнәр (вазыйфа) буенча аның дәвамлылыгын күрсәтеп, һөнәрләр (вазыйфалар) исемлеге;

в) хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүгә рөхсәте булган белем бирү оешмаларында хезмәтне саклау буенча әзерлек узучы хезмәткәрләр (вазыйфалар) исемлеге;

г) эш бирүчедә хезмәтне саклау буенча әзерлек узучы хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исемлеге;

д) эш урынында беренчел инструктаж узудан азат ителгән хезмәткәрләр (вазыйфалар) исемлеге;

е) эш бирүченең структур бүлекчәләрендә эш урынында хезмәтне саклау буенча инструктаж үткәрү, хезмәтне саклау буенча стажировка үткәрү өчен җаваплы хезмәткәрләр;

ж) хезмәтне саклау буенча инструктаж программасына кертелә торган сораулар;

з) хезмәтне саклау таләпләрен белүне тикшерү буенча эш бирүче комиссиясе составы;

и) эш бирүче комиссиясенең хезмәтне саклау таләпләрен белүләрен тикшерү буенча эш регламенты;

к) эш бирүче комиссиясендә хезмәткәрләр белемнәрен тикшерү уза торган хезмәтне саклау буенча сораулар исемлеге;

л) производствода һәлакәтләр һәм бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча әзерлекне оештыру тәртибе;

м) хезмәтне саклау буенча инструктаж оештыру һәм үткәрү тәртибе;

н) эш урынында стажировка оештыру һәм үткәрү һәм хезмәтне саклау буенча әзерлек тәртибе.

13. Хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне әзерләү процедурасын оештыру барышында эш бирүче хезмәткәрләрне алар башкарган эшләрнең характерыннан һәм эчтәлегеннән, үз вазыйфаи бурычларын куркынычсыз үтәү өчен кирәкле квалификациясе һәм компетентлыгыннан чыгып әзерләү кирәклеген исәпкә ала.

14. Эш бирүче, үз эшчәнлегенең үзенчәлегеннән чыгып, хезмәт шартларын бәяләү процедурасын оештыру һәм үткәрү максатында түбәндәгеләрне билгели:

а) хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру буенча комиссия төзү һәм эшләү тәртибе, шулай ук аның әгъзаларының хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы;

б) эш бирүчедә аерым структур бүлекчәләр булганда хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру буенча комиссия эшчәнлегенең үзенчәлекләре;

в) эш бирүченең эш урыннарында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүнең хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү буенча комиссия эшчәнлеге өлешендә оештыру тәртибе;

г) хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрүче оешманы сайлап алу һәм аның белән гражданлык-хокукый шартнамәне, әлеге эшкә эш бирүченең эшчәнлек төренә карата иң компетентлысын җәлеп итү зарурлыгын исәпкә алып, төзү тәртибе;

д) хезмәт шартларын махсус бәяләү мәсьәләләре буенча бәхәсләрне җайга салу тәртибе;

е) хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләрен куллану тәртибе.

## VI. Процедураларны тормышка ашыру чараларын планлаштыру

16. Процедураларны тормышка ашыру буенча чараларны планлаштыру максаты белән эш бирүче процедураларны гамәлгә ашыру буенча чаралар планын (алга таба – план) әзерләү, яңадан карау һәм актуальләштерү тәртибен билгели.

17. Планда түбәндәгеләр чагыла:

а) хезмәтне саклау буенча комитет (комиссия) (булган очракта) яки эш бирүче тарафыннан эш бирүчедә хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау торышы анализы нәтиҗәләре;

б) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларның гомуми исемлеге;

в) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган һәр чара буенча көтелгән нәтиҗә;

г) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган һәр чара буенча гамәлгә ашыру сроклары;

д) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларны башкару өчен һәр дәрәҗәдә җаваплы затлар;

е) процедураларны гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларны финанслау чыганагы.

## VII. Системаның эшләвен контрольдә тоту һәм процедураларны гамәлгә ашыруга мониторинг

18. Системаның эшләвен һәм процедураларны гамәлгә ашыруны котрольдә тотуны оештыру максатында, эш бирүче түбәндәгеләрне тәэмин итүче чараларны гамәлгә ашыру тәртибен билгели:

а) хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның хезмәтне саклау таләпләренә, хезмәтне саклау буенча килешүләргә туры килүен бәяләү;

б) процедураларның нәтиҗәлелеген һәм файдалылыгын билгеләү өчен мәгълүмат алу;

в) системаны камилләштерү буенча карарлар кабул итү өчен нигез тәшкил итүче мәгълүматларны алу.

19. Эш бирүче системаның эшләвен контрольдә тотуның һәм процедураларны тормышка ашыруның төп төрләрен билгели, аларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

а) эш урынының торышын контрольдә тоту, һөнәри куркынычларны ачыклау, шулай ук даими рәвештә гамәлгә ашырыла торган хезмәтне саклау буенча башка чараларны тормышка ашыру, процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләренә мониторинг ясау;

20. Системаның эшләвен контрольдә тотуның нәтиҗәлелеген арттыру һәм процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен һәр дәрәҗәдә мониторинглау өчен, эш бирүче системаның эшләвен контрольдә тотуның һәм процедураларны гамәлгә ашыру күрсәткечләрен мониторинглауның баскычлы формаларын кертә.

## VIII. Система эшчәнлеген яхшыртуны планлаштыру

21. Системаның эшләвен яхшыртуны планлаштыруны оештыру максаты белән, эш бирүче системаның эшләвен яхшыртуның система эшләвен контрольдә тоту һәм процедураларны гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләренә бәйле булуын билгели, шулай ук аварияләрне, бәхетсезлек очракларын, һөнәри авыруларны тикшерү нәтиҗәләрен, дәүләт хакимияте органнарының контроль-күзәтчелек чаралары нәтиҗәләрен, хезмәткәрләрнең һәм (яки) алар вәкаләт биргән органнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу мәҗбүри.

22. Системаның эшләвен яхшыртуны планлаштырганда, эш бирүче система эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген анализлый, ул түбәндәге күрсәткечләрне бәяләүне күздә тота:

а) хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүченең максатларына ирешү дәрәҗәсе;

б) системаның хезмәтне саклау сәясәтендә чагылдырылган эш бирүче бурычларын үтәүне тәэмин итү сәләте;

в) система эшчәнлеге нәтиҗәлелеген алдагы анализлау нәтиҗәләре буенча идарә итүнең барлык дәрәҗәләрендә эш бирүче тарафыннан билгеләнгән гамәлләрнең нәтиҗәлелеге;

г) системаны үзгәртү зарурлыгы, хезмәтне саклау өлкәсендә максатларга төзәтмәләр кертүне дә кертеп, эш бирүче вазыйфаи затларының хезмәтне саклау өлкәсендә бурычларын яңадан бүлү, эш бирүче ресурсларын яңадан бүлү;

д) системаны үзгәртү турында карарлар кагылучы хезмәткәрләрне үз вакытында әзерләүне тәэмин итү зарурлыгы;

е) системаның эшләү нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын үзгәртү зарурлыгы.

## IX. Аварияләргә, бәхетсезлек очракларына һәм һөнәри авыруларга реакция

23. Куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итү һәм саклау, һөнәри авырулар очракларына юл куймау максатыннан, эш бирүче сәбәпләрне ачыклау тәртибен һәм килеп чыккан очракта гамәлләр тәртибен билгели.

## X. Система документлары белән идарә итү

25. Система документлары белән идарә итүне оештыру максатында, эш бирүче системаның структурасын, хезмәтне саклау өлкәсендә эш бирүченең һәр структур бүлекчәсе һәм конкрет башкаручысы өчен бурычларны һәм җаваплылыкны, хезмәтне саклауны һәм контрольне тәэмин итү процессларын, эш бирүченең структур бүлекчәләре арасында системаның эшләвен тәэмин итүче кирәкле бәйләнешләрне үз эченә алган локаль норматив актларны һәм башка документларны рәсмиләштерү буенча формаларны һәм рекомендацияләрне билгели.

26. Система документларын эшләү һәм раслау өчен җаваплы затлар эш бирүче тарафыннан барлык идарә итү дәрәҗәләрендә билгеләнә. Эш бирүче тарафыннан шулай ук система документларын эшләү, килештерү, раслау һәм яңадан карау тәртибе, аларны саклау сроклары билгеләнә.

27. Системаның яңадан каралырга, актуальләштерелергә, яңартылырга һәм үзгәртелергә тиеш булмаган документларының аерым төре буларак, системаның контроль-хисап документлары билгеләнә, түбәндәгеләрне дә кертеп:

а) системаны гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган актлар һәм башка мәгълүмат язмалары;

б) исәпкә алу журналлары һәм һөнәри авырулар турында мәгълүматлар язмасы актлары;

в) җитештерү тирәлегенең һәм хезмәт процессының хезмәткәрләргә зарарлы (куркыныч) факторлары йогынтысы һәм хезмәт шартларын һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлеге торышын күзәтү турында мәгълүматлар язмасы;

г) система эшләвен контрольдә тоту нәтиҗәләре.